ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» декабрь 2022ел № 304

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 01.12.2021 елның 399 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3 өлешенең 3.2 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына идарә органнары, җирле үзидарә органнары, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнары тарафыннан беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 01.12.2021 елның 399 номерлы карарына беркетелгән үзгәрешне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **Р.Р.Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма комитетының
05.12.2022 елның 304 номерлы карары белән
расланды

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 01.12.2021 елның 399 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр**

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 043-Финанс-бюджет палатасы» бүлеген Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторлары исемлеген раслау турында» 01.12.2021 елның 399 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджеты керемнәре баш администраторлары исемлеген түбәндәге эчтәлекле бюджет классификациясе кодлары белән тулыландырырга:

| Бюджет классификациясе коды | | Бюджет керемнәренең баш администраторы атамасы |
|---|---|---|
| керемнәрнең баш администраторы | бюджет керемнәренең төрләре | |
| 043 | 2 02 20302 05 0000 150 | Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү чараларын тәэмин итү өчен муниципаль районнар бюджетларына субсидияләр, шул исәптән азкатлы торак төзелешен бюджет акчалары хисабына гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү |
| 043 | 2 02 20299 05 0000 150 | Азкатлы торак төзелешен үстерү кирәклеген исәпкә алып, гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү, шул исәптән гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү чараларын тәэмин итүгә муниципаль районнар бюджетларына торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фондыннан дәүләт корпорациясеннән кергән акчалар исәбеннән субсидияләр |